ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«10» ноябрь, 2021 ел Түбән Суык-Су № 16

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Мажын авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Түбән Суык-Су авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 20 ноябренә 13.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Мажын авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Крәшен Мажын авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Юлларны ремонтлау (Үзәк ур.)
- Урамнарны яктырту, җиһаз сатып алу (алу, урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Крәшен Мажын авылы, Үзәк урам, 18.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Ихсанов